| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 29 » 04 2020 № 267

Аксубаево

Аксубай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең эшләми торган көннәр дип игълан ителгән чорында эшләве хакында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Эшләми торган көннәрдә балалар бакчаларында абонент түләвен бетерү турында» 29.04.2020 ел, № 4921/20 хаты нигезендә һәм яңа коронавирус инфекциясе таралуга бәйле хәлнең начараюы шартларында халыкның нормаль тормыш шартларын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты:

КАРАР БИРӘ:

1. Аксубай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә тәрбияләнүчеләрне 2020 елның 30 мартыннан алып санитар-эпидемиологик хәлне яхшыртуга кадәр кабул итүне туктатырга.
2. Эшләми торган атналары дип игълан ителгән чорында, 30 марттан һәм санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчы, мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында (алга таба – Учреждение), Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә эшләми торган көннәре дип игълан итү турында» 25.03.20 ел, № 206 Указы белән билгеләнгән, җәмгыятьнең кирәкле тормыш эшчәнлеген тәэмин итүче структураларда икесе дә (яки тулы булмаган гаиләдә бер) эшләүче ата-аналар (законлы вәкилләр) гарызнамәләре буенча тәрбияләнүчеләр өчен дежур төркемнәр оештырырга.
3. 2020 елның 1 апреленнән һәм аннан соңгы боерыкка кадәр, коронавирус белән бәйле рәвештә, балалар бакчасына йөрми торган тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарын (законлы вәкилләрен) мәҗбүри үз-үзеңне изоляцияләү чорында, балаларны карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итәргә.
4. Аксубай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны тукландыру өлешендә тукландыру өчен дежур төркемнәргә йөрүче балалар өчен ата-аналар түләве күрсәтелгән чорда баланың балалар бакчасына йөрүен факттагы көннәрдә исәпләргә.

5. Әлеге карар 2020 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
6. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Александровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф.Горбунов